*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Нинди ямьле безнең туган яклар:
   Киң елгалар, яшел тугайлар!

   Безнең куе урман хәтеремдә һаман:
   Иснәр идем хуш исләрен!
   Чыгар идем кырга яратып тыңларга
   Жәйге жилләрнең көйләрен!

Җилләр исә, җилләр исә
Безнең якларда гына.
Җилләрем шулай искәндә
Йөрәгем дулкынлана!

Җилләр исә, җилләр исә,
Чайкала иген кыры.
Шул якларда мине сагынып
Көтә бит сөйгән ярым!

2. Туган авылым, сәлам сиңа, сәлам!
   Сөям сине бар йөрәгем белән.

   Монда күргәннәрем, гомер сөргәннәрем
   Онытылмас, кайда йөрсәм дә.
   Әнкәйнең көйләре, изге теләкләре
   Мәңге яшәр күңелемдә.

.

3. Илтте язмыш мине ерак җиргә.
   Ярый микән язмышка рәнжергә?

   Хисләргә бирелеп, сагышка күмелеп,
   Кичеп үтәм һәр төнемне.
   Туган илкәемә, сөйгән җиркәемә
   Әле кайтырмын бер көнне!

*Ветры дуют, ветры дуют*
*Далеко, в родных краях.*
*Где зазывно ветры дуют,*
*Там живет любовь моя…*